Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№12 (105)
17 апрель 2014 ел



Влад Михневский фотосы

# Тукай монументы – Казанда да, Каһирәдә дә!

Урамда яз, апрель... Күбебез өчен апрель Тукай ае буларак билгеле. Ник дигәндә, бу айны, гадәттә, татар җәмәгатьчелеге шагыйрь Габдулла Тукайга багышлый. КФУда да Тукайны онытмыйлар. Дәвамы 2 биттә

## Вакыйгалар эзеннән

**9-13 АПРЕЛЬ** көннәрендә Санкт-Петербургта юниорлар арасында пауэрлифтинг буенча **ЕВРОПА ЧЕМПИОНАТЫ БУЛДЫ**. Биредә 25 илдән 150 спортчы көч сынашты. Россия җыелма командасы составында Алабуга институтының физик тәрбия факультеты студенты А.Филимонова да чыгыш ясады. Ул 52 килограммга кадәрге авырлык категориясендә 5 алтын медаль яулады.

• • • •

**12 АПРЕЛЬДӘ** Казанда грамоталы язу культурасын үстерүгә юнәлтелгән **«ТОТАЛЬ ДИКТАНТ» АКЦИЯСЕ УЗДЫ**. Бу диктантны Казан университетының төп бинасы аудиторияләрендә дә яздылар. Быел акция аеруча популяр булды. Рус теле грамматикасы өлкәсендәге белемнәрен меңнән артык кеше сынап карады.

• • • •

Шул ук көнне КФУда **«БЕРДӘМЛЕК КҮПТӨРЛЕЛЕКТӘ: ЕВРОПА СОЮЗЫ БҮГЕН»** Бөтенроссия конференциясе үз эшен башлап җибәрде. Конференциянең ике көнлек программасында Халыкара һәм Европа хокукы өлкәсендәге алдынгы белгечләрнең лекция һәм тренинглары бар. Өстәвенә, Казанга Европа тематикасы буенча Бөтенроссия интеллектуаль олимпиадасында катнашучылар да җыелды. «Европа XXI гасырда» дип аталган серия конкурсы катнашучылары конференциядә «Кеше хокуклары:Россия һәм ЕС» темасына язылган эсселарын һәм проектларын яклады.

• • • •

**14 АПРЕЛЬДӘ** ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Иң беренче булып, гадәттәгечә, административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм алдагы атнада булачак вакыйгалар хакында мәгълүмат бирде. Алга таба **И.ГАФУРОВ** ремонт эшләре турында сөйләде. Төзекләндерү эшләре иң элек II корпус, Яр Чаллы һәм Алабуга институтларында булачак. Алдагы мәсьәлә яңа структуралар булдыруга бәйле иде. Якын киләчәктә Экология һәм география институты белән Н.И.Лобачевский исемендәге математика һәм механика институтының уртак аэрозольләр институтара лабораториясе; ТР Алабуга шәһәр суды каршында җинаять процессы, хокук саклау һәм суд эшчәнлеге экстерриториаль кафедрасы оешачак. Ахырдан Белем бирү ресурсларын үстерү департаменты директоры **Г.ИВШИНА** «КФУда электрон белем бирү системасы» проектын гамәлгә ашыру турында сөйләде.

• • • •

**14 АПРЕЛЬ** көнне КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** КФУның **ЯР ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫНА ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Институт директоры М.Ганиев белән берлектә, КАМАЗның элекке китапханәсендә урнашкан социаль-гуманитар бүлек биналарын карады. Шулай ук ректор КФУның Инжиниринг үзәгендә дә булды. Бүгенге көндә аны җиһазландыру эшләре бара.

• • • •

**15 АПРЕЛЬ** көнне **КФУ** һәм Кытайның **СИНЬЦЗЯН УНИВЕРСИТЕТЫ** арасында үзара **ХЕЗМӘТТӘШЛЕК** турында **КИЛЕШҮ ТӨЗЕЛДЕ**. Чара Кытайның Синьцзян-Уйгыр автоном районының Урумчи шәһәрендә ТР президенты Р.Миңнеханов җитәкчелегендә Татарстан делегациясенең визиты кысаларында узды. Делегация составында КФУны тышкы эшләр буенча проректор Л.Латыйпов бар иде.

• • • •

**16 АПРЕЛЬ** көнне Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтында югары сыйныф укучылары өчен «Төрле буын, чор һәм халыклар мәдәнияте» исемле **ТӨБӘКАРА ОЛИМПИАДА УЗДЫ**. Анда мәктәп укучылары мәдәният тарихы буенча белемнәрен күрсәттеләр.

• • • •

**18-19 АПРЕЛЬ** көннәрендә КФУның юридик факультеты базасында яшь юристларның **«БӨТЕНРОССИЯ СУД ДЕБАТЛАРЫ 2014» КОНКУРСЫ УЗДЫРЫЛАЧАК**. 2005 үткәрелә торган конкурс быел да үзендә Мәскәү, Санкт-Петербург, Самара, Сахалин кебек күп кенә шәһәрләрдән командалар кабул итәчәк. Чара гражданлык һәм җинаять процесслары юнәлешләре буенча үтәчәк. Суд каршында ышанычлы нотыклары белән чыгыш ясап, студентлар үз позицияләрен дәгъвачы һәм җавапка тартылучы буларак та яклаячаклар.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Эшлекле сөйләшү

# Максатларыбыз уртак

Алинә САДЫЙКОВА

15 апрель көнне КФУда ТР югары уку йортларының җитәкчеләре бергә җыелып, чираттагы Ректорлар Советы утырышын уздырды.



Иң элек Россия Президенты грантына ия булган җиңүчеләрне бүләкләү һәм таныклык тапшыру тантанасы булды. Аны Ректорлар советы рәисе, КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм ТРның Мәгариф һәм фән министры урынбасары Данил Мостафин тапшырды. Конкурста катнашкан 11 җиңүче арасында КФУ галимнәре дә бар: Т.Абдуллин (фән кандидаты), И.Кәлимуллин (фән докторы), А.Ризванов (фән докторы), А.Фролов (фән кандидаты).

Алга таба ТР югары уку йортларында милли мәгариф үсеше мәсьәләләре хакында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, профессор Р.Жамалетдинов сөйләде. Әлеге юнәлешнең эшчәнлеген көчәйтү өчен, 2012 елның 21 мартында махсус Вузара координацион совет оеша. 2013/2014 уку елында үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, түбәндәгеләр билгеле була. Республикабыз вузларында филологик булмаган факультетларда рус һәм татар телен берничә уку йорты студентлары гына өйрәнә. Ул да булса, Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм академиясе, Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты, Социаль белем бирү академиясе һәм Казан дәүләт энергетика университетлары. Калган вузларда телләрне өйрәнүчеләр 9-52% тәшкил итә. Казан кооперация институты һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтында исә татар теле бөтенләй укытылмый икән.

Фәнни-методик эшчәнлекне оештыру ике юнәлештә алып барылган: профессор-укытучылар составының квалификациясен күтәрү һәм фәнни-методик комплекслар төзү. Бу юнәлеш буенча планлаштырылган эшләр үтәлгән. «Ана теле» онлайн-мәктәп проектын булдыру, Казан Лингвистик үзәген ачу, «Татарика» халыкара журналын бастыра башлау – болар барысы да шуңа дәлил булып тора. Алай гына да түгел, Вузара координацион совет вәкилләре һәм республикабызның башка вуз укытучылары татар, рус телен үстерү һәм саклап калуга юнәлтелгән норматив-хокукый документлар эшкәртү буенча актив эшли.

Р.Жамалетдиновның чыгышын Казан Дәүләт архитектура-төзелеш университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры Илфак Вилданов дәвам итте. Ул шушы уку йортында татар телен укыту торышы белән таныштырды. Биредә чиста татар төркемнәре дә бар икән.



Влад Михневский фотолары

ТР Студентлар лигасы президенты Э.Искәндәров республикада белем ала торган чит ил студентлары, аларны борчыган мәсьәләр хакында җиткерде.

«ТИСБИ» идарә академиясе ректоры Н.Прусс физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр белән эшли торган республика вузара үзәгенең эшчәнлеге белән таныштырды. Нелла ханым шулай ук хәзерге студентларның кальян тарту белән мавыгуларына борчылуын җиткерде. Утырыш вәкилләре бу мәсьәләне Хөкүмәт аша хәл итәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Бу идеяне дәвам итеп, Казан дәүләт медицина университеты ректоры А.Созинов тәмәке тарту, аның зыяны һәм әлеге проблема белән көрәш алып бару хакында сөйләде.

Татарстанның Яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Р.Гарифуллин республикабыз вузларындагы хезмәт отрядларының эшчәнлеге һәм 2013 елгы нәтиҗәләр белән таныштырды. Чыгышының ахырында ТР Хөкүмәте исеменнән КФУ ректоры И.Гафуровка студентлар хезмәт отряды эшчәнлегендә актив катнашканы һәм булышлык күрсәткәне өчен рәхмәт хаты тапшырды.

Бу көнне Ректорлар Советы составына тагын ике вәкил: Икътисад, идарә һәм хокук институты ректоры А.Тимирясова һәм Социаль белем бирү академиясе ректоры И.Мөхәммәтҗанов өстәлде. Ахырда Ректорлар Советы Кырымда күчмә утырыш уздырырга дигән фикергә килде. Бу Кырым абитуриентларын җәлеп итү йөзеннән башкарылачак. И.Гафуров сүзләренчә, делегациянең составы соңрак билгеләнәчәк, очрашу исә май урталарына планлаштырыла.

• Киңәшмә

# Беренче курстан – мәктәпкә!

15 апрель көнне КФУда Педагогик белем бирү буенча Координацион совет утырышы узды.



Инны Басырова фотосы

Чарада ТРның Премьер-министр урынбасары – Мәгариф һәм фән министры **Энгель Фәттахов**, КФУ ректоры **Илшат Гафуров**, советның башка әгъзалары – министрлык галимнәре, КФУ һәм Мәгарифне үстерү институты вәкилләре дә катнашты.

Беренче булып чыгыш ясаган министр педагогик кадрларны әзерләүгә басым ясады. «Безнең республикада укытучыларны әзерләү белән 10 колледж, КФУ, КФУның Алабуга институты, Яр Чаллының социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты шөгыльләнә. Ләкин мәктәпләргә уку йортын тәмамлаганнарның 40 проценты гына барып җитә, авыллар турында әйтмим дә. Бу проблеманы тиз арада хәл итәргә кирәк», – диде Э.Фәттахов. Әлеге мәсьәлә чишелешенә төрле факторлар комачауларга мөмкин. Министр сүзләренчә, булачак укытучыларның психологик-педагогик әзерлегенең түбән дәрәҗәдә булуы, шушы өлкәгә бәйле соңгы яңалыклардан хәбәрдар булмавы, авыр холыклы яисә талантлы яшүсмерләр белән эшләргә әзер түгеллеге шуларның берничәсе генә. Ул педагогик кадрларны яңадан әзерләү һәм квалификацияне күтәрүгә зур игътибар бирелергә тиешлеге турында әйтте. 2014 елда 15249 мәгариф хезмәткәре белемен арттырачак.

Алга таба ректор И.Гафуров, министр чыгышын дәвам итеп, бу проблема турында үз фикерләрен җиткерде. «Педагогик кадрлар әзерләү – КФУның социаль бурычы. Бездә 6 меңнән артык булачак укытучы әзерләнә. 2013 елда уку йортыбыз психологик-педагогик белем бирү сыйфаты буенча илдә дүртенче урынга лаек булды. Педагогларны әзерләү буенча без төзегән модельдән башка федераль университетлар да файдалана», – дип белдерде ул. Ректор фикеренчә, педагогик белем бирү сыйфатын үстерү өчен, аның структурасын төптән үзгәртергә һәм технологияләрне заманчалаштырырга кирәк. Министрның укытучыларны авылларга җәлеп итү фикеренә каршы: «Бу очракта аларны башта торак белән тәэмин итәргә кирәк», – диде.

Психология һәм мәгариф институтының гомуми һәм социаль педагогика кафедрасы җитәкчесе Р.Вәлиева бу проблемаларның чишелен педагогика һәм психология фәннәрен бөтен уку дәверендә укытуда, өзлексез практика оештыруда күрә.

Чыгышлардан соң, советның башка әгъзалары да фикерләре белән уртаклашты. Кызыклы гына тәкъдимнәр яңгырады. Бирегә җыелган барлык катнашучыларны да борчыган заман укытучысын әзерләү проблемасы, һичшиксез, чишелешсез калмас.

• Тугандаш халыклар

Язның нәкъ уртасы – 15 апрель көнендә Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтында мәшһүр Тукайга һәм күренекле гарәп язучысы, фәлсәфәчесе Аббас Мәхмүд әл- Әккадка бюст ачтылар.

# Тукай монументы – Казанда да, Каһирәдә дә!

Ләйсән ИСХАКОВА,
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Сыннарның ачылышы тантаналы рәвештә узды. Ике баш-сынның да авторы – күренекле мисыр сынчысы, Мисыр Гарәп Республикасының Мәскәүдәге вәкиллегенең мәдәният мәсьәләләре буенча киңәшчесе Усама әл-Сәрви. Ул үзе дә тантанада чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, сыннар бик җиңел һәм тиз вакыт аралыгында эшләнгән. Усама әл-Сәрви институт директоры Рамил Хәйретдиновка Мисыр вәкиллеге исеменнән Мисыр мәгариф министрлыгы гербы төшерелгән истәлекле бүләк тапшырды.

Узган ел ахырында Мисыр һәм Россия арасындагы дипломатик һәм дуслык мөнәсәбәтләренә 70 ел тулды. Әлеге мөнәсәбәтләрне ныгыту бүген дә дәвам итә. Усама әл-Сәрви шундый ук монументларның якын киләчәктә Каһирә дәүләт университетында да куелачагын әйтеп узды. Димәк, Тукайны Мисырда да беләләр һәм хөрмәтлиләр. Р.Хәйретдинов исә, үз чыгышында, иҗади һәм дустанә мөнәсәбәт күрсәтүләре өчен кунакларга рәхмәтен җиткерде. «Киләчәгебез һәм уртак якларыбыз турында сөйләгәндә, мәдәниятнең безне берләштерә торган көч булуы хакында искәртү мөһим. Гарәп мәдәнияте узган гасырларда мәшһүр язучыларыбыз иҗатына аеруча ачык чагыла», – дип белдерде ул үз чыгышында. Директор, шул рәвешле, тантананың гарәп илләре белән халыкара мөнәсәбәтләрне ныгытудагы әһәмиятен билгеләп үтте. Чыннан да, Ислам динен кабул иткәннән бирле, татар халкы гарәп дөньясы белән тыгыз бәйләнештә яши. Бу хакта Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры Ф.Галимуллин да сөйләде: «Гарәп теле безгә бик якын. XX гасыр башында яшәп иҗат иткән әдипләребез гарәп телендә укый белгән. Алай гына түгел, хәтта гарәпчә язганнар да. Г.Тукай иҗатына да гарәп теле, әдәбияты, мәдәнияте көчле йогынты ясаган».

Гарәп кунаклары исә үзләренең дәһи шәхесләре белән якыннанрак таныштырды. Аббас Мәхмүд әл-Аккад – күренекле гарәп язучысы, публицист һәм әдәби тәнкыйтьче. Әдип 1889-1964 елларда яшәп иҗат иткән. Ярлылыгы аркасында башлангыч белем генә алган, шулай да зур тормыш сынаулары аша үтеп, үзлегеннән укып, тырышып югары дәрәҗәләргә ирешкән. Шул рәвешле, чара студентларга һәм килгән кунакларга гарәп һәм татар мәдәниятләренең үзара тыгыз бәйләнеше һәм Аббас Мәхмүд әл-Аккадның кем булуы хакында тагын бер кат искә төшерде.

• Гасыр бөҗралары

# Җуелмас байлыклар мәгарәсе

Иң зур байлык кайда була, дисезме? Җир астында, урманда, сулыкларда, әллә инде кибет-банклардамы? Һәркайсында бар! Ләкин аларга ия булу өчен, дөньядагы иң зур байлык – китапка мөрәҗәгать итәбез. Ә уку йортыбызның Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге тарихы университетныкы кебек үк, бик ерака барып тоташа.



Уку йортының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә – Россиянең иң эре һәм борынгы китапханәләренең берсе. Аңа, Казан университеты белән бергә 1804 елда нигез салына. Ул Казан гимназиясе китапханәсе фонды базасында оеша.

Китапханәнең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге серле китаплар мәгарәсен хәтерләтә. Биредә шәрык кульязмаларын җыю традициясе 1807 елдан кертелә, узган гасырның 30нчы елларында университет китапханәсендә татар голәмәләренең шәхси милкендәге гарәп шрифтында булган кульязмалар һәм китаплар керә башлый. 1963 елдан башлап, биредә университетның татар галимнәре Россиянең төрле төбәкләренә оештырылган археографик экспедицияләрдән алып кайткан меңләгән китаплар тупланган.

Китапханәнең үсешендә бөек рус галиме Н.И.Лобачевский аеруча зур роль уйный. 1825 елда ул китапханәче итеп сайлана, 1835 елга кадәр аны җитәкли, шул исәптән 1827 елдан башлап ректор вазифасын да башкара. Ул эшләгән заманда китапханә шактый үзгәрешләр кичерә: фондны комплектацияләү, бердәм каталог булдыру, шәһәр халкына китаплардан файдалану мөмкинлеге тудыру һ.б.

XIX гасырның икенче яртысында китапханә Казан университетында басылган кульязмаларны бүләк итү хисабына байый. Коллекция бигрәк тә гарәп һәм фарсы телләре буенча ординар профессор И.Ф.Готвальд ярдәме белән тулылана. Ул 1985 елда гарәп графикасында язылган 111 кульязма бүләк итә. Готвальд 6 ел китапханәче булып та эшли. Шулай ук университет типографиясен җитәкли. Ул эшләгән чорда китапханә бинасы янына, аны зурайту максатыннан, зур корылма төзелә. 1897 елда Готвальдның кызы Ж.И.Крелленберг университетка, әтисенең васыяте буенча, аның шәхси китапханәсен бүләк итә. Анда тагын бик күп татар, гарәп һәм фарсы телләрендә язылган кульязмалар була.

Казан университеты китапханәсендә җыелган кульязмалар саны 13 меңнән арта. Шуларның иң күп өлешен татарча язылган китаплар тәшкил итә. Гарәп телендәге күчерелмә китаплар алардан азрак. Фарсы телендәгеләр чагыштырмача күпкә ким, чөнки фарсылар үзләре дә гарәпчә язганнар. Бөтен мөселман халыклары дини, фәнни әсәрләрне гарәп телендә язарга тырышканнар. Ул мөселман көнчыгышында фән теле булган. Әмма соңга таба, XV-XVI гасырлардан башлап, төрки-фарсы телләрендә язылганнары арта барган.

Бүлектә безнең көннәргә килеп җиткән уникаль нөсхәләр бар, китапханәдә аларны күз карасыдай кадерләп саклыйлар. Биредә бабаларыбыздан калган кулдан күчереп язган мусхаф әш-шәриф (кульязма Коръән) нөсхәләре һәм 1917 елга хәтле нәшер ителгән Коръән китаплары, шул исәптән дөнья күләм мәшһүр Казан басмалары саклана. Китапханәдә изге китап күчермәләре барлыгы 150дән артып китә. Кайбер кульязмаларны басмалардан аерып булмый, чөнки алар шул кадәр вак, нәфис бизәкләр белән бизәлгән һәм тигез, камил итеп кулдан язылган, гаҗәпкә каласың.



■ Татар әлифбасы. 1812 ел.

■ Ә.Фирдәүси «Шаһлар китабы» (910-1030 еллар)

1917 елның октябренә кадәр Россиядә татар китабын бастыручылар 30 миллион тираж белән татар, гарәп, фарсы һәм башка төрки телләрдә 15 мең китап чыгара. Ә китапханәдә Россиядә басылган китаплар гына түгел, ә Бейрут, Дели, Каир, Истамбул, Рим, Лейпцигта дөнья күргәннәр дә саклана.

Россия империясе һәм СССР дәверендә (1905-1924 елларда) гарәп графикасы белән 310 газета һәм 89 журнал чыга. Аларның тулы коллекциясе шулай ук әлеге бүлектә урын алган.

1963 елдан башлап, уку йортында һәр ел саен археографик экспедиция оештырыла. Алар бүгенге көндә дә Россиянең төрле төбәкләреннән гарәп графикасы белән язылган кульязмалар табып кайта.

***P.S.** Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенә рәхим итегез. Андагы мохит сезне бик еракка алып китәр. Вакыт машинасы нәкъ менә бүлектә сакланган кульязмаларда, китапларда, тарихи документларда чагыла икән. Ә алдагы саннарда бай мирасыбыз белән җентекләп таныштырырбыз.*

• Очрашу

КФУның Идел буе Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәгендә Республика районнарыннан килгән укытучылар белән язучы Нурислам Хәсәнов очрашты.

# Тормыш тәҗрибәсе чагылган иҗат

**Сиринә ТРОФИМОВА**



Әдипнең бүгенге һәм элекке иҗаты турында сүз барышында якты гына хатирәләр искә төште, аның теге яки бу әсәре турында фикер алыштык. Нурислам ага иҗаты күп санлы укучыларга, укытучыларга да байтактан таныш. Авторның тәрбия, әдәп-әхлак проблемаларын ачык, калку чагылдырган һәм укучылар күңеленә барып ирешерлек итеп, яшьләр тормышын, аларның психологиясен белеп язылган «Бәхилләрме йәрәк?» повестен кемнәр генә укымагандыр?!

Иҗатта да, тәрбия эшендә дә уңышка ирешү өчен, язучыга зур тормыш тәҗрибәсе тупларга кирәк. Эшчеләр мохитендә чыныгу алган инженер-механик Н.Хәсәновка, реаль чынбарлыгыбызны чагылдыру өчен, шушы бай тәҗрибәсен тулысынча файдаланган. Без моның шулай икәнен аның «Инешемдә – гомер агышы», «Тәкъдир», «Ак балык», «Иңрәү», «Хакыйкать хакы», «Дан авазы» повестьларын укып та беләбез. Ул кешеләр язмышындагы драматик вакыйгаларны тотып ала һәм нәкъ үз урынында куллана, кыю рәвештә укучылар күңелен җәлеп итәрлек итеп сурәтли дә белә.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, аның «Хәтер» нәшрияты инде менә ничә еллар, «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән Ш.Камал, Г.Бәширов, М.Әмир, Ф.Хөсни, И.Гази һ.б. әдипләребезнең китапларын күпләгән тиражда баса килә. Һәм, ниһаять, шушы сериядә Н.Хәсәновның да сайланма әсәрләре 2012 елда дөнья күрде, республика мәктәпләренә барып иреште. Очраклы хәлме бу? Юк. Н.Хәсәновның иҗаты, бигрәк тә повестьлары, җәмгыятебезнең намусын-әхлагын сафландыруга, гаделлек өчен көрәшкә юнәлдерелгән.

Укытучылар белән очрашуда авторга күп төрле сораулар бирелде. Н.Хәсәнов үзе дә юмористик парчаларын укыды. Әдәбият турында сөйләшү, фикер алышулар бик җылы төстә узды. Аннары очрашуда катнашучылар авторның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителүен хуплап, аның бу мәртәбәле исемгә лаеклы булуын да белдерде.

• Мөнбәр

# Эшмәкәр-укучылар уңышы

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Халыкара мәктәп бизнес-компанияләре фестивалендә Н.И.Лобачевский исемендәге лицей укучыларының «Education 2.0» проекты иң инновацион һәм иҗтимагый әһәмиятле дип танылды.

Әлеге фестиваль 7-9 апрель көннәрендә Латвиянең башкаласы Рига шәһәрендә үтте. Чарада 16 илдән 85 команда катнашты. Алар арасында Норвегия, Швеция, Финляндия, Нидерланд, Германия, Австрия, Төркиядән килгән командалар бар иде. Россияне 6 команда: Мәскәүдән – 3, Екатеринбургтан – 1, Казаннан 2 команда тәкъдим итте. Шулар арасында КФУның Н.И.Лобачесвкий исемендәге лицей укучылары да бар иде. Лицейданын 11С сыйныф укучылары Владислар Минин белән Екатерина Седова, 11Е сыйныф укучысы Елена Боглаевская һәм 10С сыйныфыннан Рафаэлла Низаева яклады.

Фестиваль программасына төрле тренинглар, Риганың бизнес университеты укытучыларының мастер-классларын һәм проектларын тәкъдим итү кертелгән иде. Беренче көнне һәр команда тренингларда катнашты. Шул ук көнне барлык катнашучыларны төрле ил вәкилләреннән торган 20 командага бүлделәр. Аларга аерым биремнәр әзерләнгән иде. Шуларны эшләгәннән соң, һәр команданың «How to cook a business?», ягъни «Бизнесны ничек төзергә?» гыйбарәсе килеп чыкты. 15 минут эчендә һәр командага да шул сорауга җавапны бер минутлык презентациядә чагылдырырга кирәк иде. Нәтиҗәдә бөтен презентацияләр дә кызыклы һәм мактауга лаеклы итеп эшләнде. «Cookies» командасының (команда капитаны – Е.Боглаевская) эше иң үзенчәлекле дип танылды һәм беренче урынга лаек булды.

Фестивальнең икенче көнендә күргәзмә-ярминкә оештырылды. Мәктәпләр төрледән-төрле бизнес-компания продукцияләрен тәкъдим итте. Нәрсә генә юк иде алар арасында! Әйтик, чиста экологик материядән эшләнгән рюкзак-сумкалар, сувенирлар, йомшак уенчыклар, сәгать беләзекләре, шәмнәр, галстуклар, ясалма чәчәкләр, бәйләгән әйберләр, күлмәк киптерү җайланмалары һ.б.




Безнең команда күргәзмә өчен КФУның Физика институты белән берлектә эшләнгән «IRIS» элементар физик экспериментларның комплект-наборларын әзерләде. Нәтиҗәдә лицей укучыларының «Education 2.0» бизнес-компания продукциясе, жюри тарафыннан югары бәяләнеп, «Most Innovative Product Award», «Social Responsible Business Award» номинацияләрендә җиңү яулады. Өстәвенә, әлеге бизнес-компания РФнең «Junior achievement» халыкара җәмәгать оешмасы вәкилләренә аеруча ошады. Алар әлеге продукцияне иң инновацион һәм иҗтимагый әһәмиятле дип тапты.

Россиядән катнашкан безнең бизнес-компания халыкара танылу алган бердәнбер компания булды. Шулай ук, «Junior achievement» халыкара җәмәгать оешмасы HP белән берлектә оештырган халыкара иҗтимагый инновацияләр фестивале (Social Innovative Relay) нәтиҗәләре буенча, лицей укучыларының «Education 2.0» компаниясе Россия мәктәпләренең иң яхшы 20 компаниясе исемлегенә керде.

Лицейның «Вожатые 2.0» бизнес-компаниясе күргәзмәгә материаллар әзерләүдә ярдәм күрсәткән Физика институтының гомуми физика кафедрасы доценты Юрий Анатольевич Захаровка, кафедра инженеры Денис Сергеевич Идрисовка зур рәхмәт белдерә. Укучыларга терәк булган һәм яңа идеяләргә илһамландырган «Достижения молодых» Казан үзәге җәмәгать оешмасы директоры Ләлә Дмитриевна Бикчәнтәевага аеруча зур рәхмәт.

***Материал «Education 2.0» командасы ярдәме белән әзерләнде***

**Премьера**

«Мизгел» яшьләр театры һәр ел саен тамашачылар игътибарына бер премьера тәкъдим итә. Былтыр алар куелышында Туфан Миңнуллинның «Саташу» пьесасын карап соклансак, быел исә – «Үзебез сайлаган язмыш» белән хозурландык.

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты






Рамил Газизов фотолары

# Уңыш телим сиңа, «МИЗГЕЛ»!

Укытучылар тормышы, коллективта туган низаг, укытучы белән укучы мәхәббәте – Т.Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәрендә нигез ташлары булган проблемалар бу. Туфан аганың әлеге драмасы 1972 елда язылган булса да, бүген дә актуальлеген югалтмый, уку йортыбызның «Мизгел» яшьләр театры тарафыннан аның кабат сәхнәгә кайтуы шуны дәлилли. Тормышта төрле хәлләр була, дияр күбегез. Әмма кискен конкуренция шартларында этле-мәчеле яшәгән, көн саен яңалык кереп торган заманда мәгариф системасына яраклаша алмыйча интеккән укытучылар коллективын бүген дә очратырга мөмкин. Әмма максатым аларны фаш итү түгел. Сүзем – залга аншлаг җыйган спектакль турында.

Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге каршында эшләп килә торган «Мизгел» театрының бу спектакльне сәхнәләштерергә алынуы, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүе символик көчкә ия, минемчә. Чөнки тамашачыларның күпчелеге, артистлар – үзләре үк булачак укытучылар.

Пьеса мәгариф өлкәсендә эшләүчеләргә тирән хөрмәт белән сугарылган булса да, төп юнәлеше белән шул чорда мәктәпләрдә нык тамыр җибәргән кимчелекләргә каршы юнәлтелгән. Әсәрдә мәктәп тормышы, аның каршылыклары, тормышның «ак» һәм «кара» күренешләре заман югарылыгына күтәрелеп хәл ителә. Мөнирә образында бирелгән кара көчләр мәктәпләрдә шактый. Шулар белән көрәшүче яшь каһарман – мәктәп директоры хәлне, мәктәптә хөкем сөргән атмосфераны яхшы аңлый. Ул туктаусыз көрәштә. Илгиз беренче педсоветта ук үзенең ялгыз түгеллегенә яхшы төшенә. Кара көчләр, барыбер үзләренекен итсәләр дә, Илгизне кусалар да, ул алардан рухи яктан, фикер сөреше белән өстен кала. Илгизнең әрнү катыш тетрәндергеч: «Уяныйк мәллә, иптәшләр!», «Үзебез сайлаган язмыш, түзәргә туры килә» – кебек гыйбарәләре тормышыбызга башка күзлектән карарга этәрә.



Мәгариф системасын чорнап алган ялган, балаларга чын белем бирмичә, өлгереш артынан куу – бу Туфан абый күрсәткән ачы хакыйкатьнең кайберләре генә. Ә бит шушы ачы хакыйкать артында күпме бала язмышы; мәктәпне тәмамлап, хыяллары тормышка ашмаган, максатына ирешүгә юлындагы киртәләрне җимерергә көч тапмаган яшь йөрәкләр, торырга мөмкин. Илгә белемле, яңа яшь көчләр бирергә тиешле мәгариф системабызның аксый башлавын Туфан ага инде үзгәртеп кору чорына кадәр үк чамалый һәм дә чаң кагарга тотына.

Сүз уңаеннан шуны әйтеп китү урынлы булыр: әлеге пьесаның яшьләр театры тарафыннан өченче тапкыр куелышы икән инде. Һәр куелыш саен – яңа труппа. Чөнки яшь көчләрне туплау, талантларга үсәргә мөмкинлек тудыру, яшьләрне сихри театр дөньясы белән таныштыру – театр режиссеры Марсель абый Җаббаровның да изге максаты.

Барыбыз да күрдек: Марсель абый кыска гына вакыт эчендә труппа туплап, сәхнәдә якты образлар тудыра алды. Актерларның дөрес сайланышы, аларның рольгә кереп, сәхнәдә үзләрен тотышлары, герой кичергән тойгыларны йөрәге аша үткәреп, бар нечкәлекләрен белеп уйнаулары таң калдырды. Төп герой – 2нче курс студенты Илназ Сибгатуллин, Нәриман булып уйнаган Илзам Хаҗиев тудырган образлар хәтердә әле озак сакланыр.

Театрда мимика, грим, декорацияләр дә әһәмиятле роль уйный. Җитди Илгизне хәтта комик образ Рамил дә көлдерә алмады. Ә И.Хаҗиев белән Э.Нәҗиповага исә грим зур тормыш тәҗрибәсе туплаган укытучы образын тудырырга ярдәм итте. Минимум декорация директор кабинетын өй мохитенә, өйнекен директор бүлмәсенә әйләндерде.

Сәхнә законнарының бер се – тормыштагыча уйнау. Образ тудырганда, аны бөтен барлыгы белән кабул итү. Шундый берничә кагыйдә актерларның оялу хисен юкка чыгара, аларга ачылырга ярдәм итә. Спектакльдә самими дә, шул ук вакытта чын мәхәббәт хисенә дә ия булган Динә образын тудырган Айгөл Миннегалиеваның бу чын дебюты иде. Беренче коймак төерле була, диләр. Бу чыгышында Айгөл 10 сыйныф укучысы образын тулысынча ачып бетерә алмаса да, Илгизне озатканда ул инде чын Динә иде.

Спектакльне бәяләргә һәр премьера саен профессиональ артистлар – Г.Камал театры осталарын чакыру матур традиция. Алар тарафыннан мактау яки тәнкыйть сүзләре ишетү – үзе бер дәрәҗә, зур җаваплылык.

Театр – шундый серле дөнья ул. Аның белән «җенләнсәң», ул сине тиз генә ычкындырмый. Спектакльдә катнашкан студентларыбызны да «Мизгел» йөгәнендә нык тотсын иде, аларга алга таба елына бер генә түгел, берничә премьера күрсәтергә насыйп булсын!

**Безнең канат**

# Шүрәлеләр дә төрле була!

**Эльвина ЛОТФУЛЛИНА,** 8 сыйныф укучысы

Казан федераль университеты каршындагы Н.И.Лобачевский исемендәге лицей укучылары һәм укытучылары өчен 11 апрель гади уку көне буларак башланып китте. Әмма бу гадәти генә көн түгел иде, без дәресләрнең бетүен зур түземсезлек белән көттек.

Ни өчен, дисезме? Нәкъ менә шул көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары безнең өчен Т.Миңнуллинның «Җанкисәккәем» комедиясен куйды.

Спектакльдә бер-берсенә капма-каршы ике дөнья сурәтләнә. Яшьләр авылдан ерак түгел урманга ял итәргә чыгалар. Төп геройларның берсе – Җәмилә. Аныңча, кешеләр дөньясы бозык. Ә иптәшләре уйлавынча, Җәмилә үзе мәдәният белән дә дус түгел, бераз ахмагракта. Ул иптәшләреннән аерылып тора, шуңа да аңа башкалар янында кызык түгел. Болында, дусларыннан аерылып, җырлап йөргән вакытта, ул Шүрәлене очрата. Шүрәле беркатлы, тиз ышанучан, романтик, тәрбияле. Урман героен кызның моңлы тавышы җәлеп итә. Кызык: алар бик тиз уртак тел табып, дуслашалар.




Җәмилә хәтта Шүрәленең Тукай Былтыры кыстырып калдырган бармакларын бүрәнә ярыгыннан чыгара, азат итә. Шулвакыт куркыныч Шүрәле дә үз мәхәббәтенең шушы туташ икәнен аңлый.

Җәмиләнең дуслары, аның бәхетле икәнен күреп, аннан көнләшә башлыйлар һәм урманга Шүрәленең дусларын эзләп китәләр. Нәтиҗәдә Шурик белән Шүркәне үзләренә гашыйк итәләр. Урман «егетләре» кызларга шигырьләр укый, җырлар багышлый, чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр. Авыл егетләре романтикадан бик ерак булганга, кызлар өчен мондый мөнәсәбәт тансык була. Шуңа алар үзләре дә «урман сарыклары»на гашыйк булалар. Ләкин бу вакытта авыл егетләре дә тик ятмый. Алар, үз чиратларында, урман «кызлары» Шүрәлия һәм Шүрәлинә белән гыйшык-мыйшык уйныйлар.

Спектакльнең азагында һәр герой үз мәхәббәтен таба, урманның искиткеч матурлыгына соклана, күңел күзе белән карый башлый. Матурлыкны күрә белү хисе геройларны, аларның тормышка һәм әйләнә-тирәгә карашларын үзгәртә.

Әсәр мине уйланырга мәҗбүр итте. Кешенең тышкы матурлыгы гына түгел, ә эчке дөньясы, аның кылган гамәлләре, уйлары, хис-тойгылары да матур, саф булырга тиешлегенә тагын бер кат инандым. Спектакль башында яшьләрнең күңелләре буш, ә уй-фикерләре бик примитив кебек иде. Ләкин урманда яшәүчеләр белән очрашкач, алар үзгәрделәр. Рухи матурлыкны күрә белергә өйрәнделәр, табигатькә, бер-берсенә хөрмәт белән карый башладылар.

Күмәкләшеп баргач, сыйныфташлар, дуслар белән спектакль турында фикер алышып, аларның ни уйлаганнарын белдем. Әсәрне минем шикелле ошатучылар күп булып чыкты. «Спектакль чыннан да бик эчтәлекле. Актерларның да образларга тулысы белән кереп китеп уйнаулары, тамашачыга тиешле дәрәҗәдә җиткерүләре сокландырды», – дип белдерде бер иптәшем. Фикеремә каршы килүчеләр дә булды: «Мәгънәсе аңлашылып бетмәде. Ләкин декорация, актерларның осталыгы яхшы тәэсир калдырды». Бәхеткә, мондый фикердәгеләр бик сирәк. Иптәшләремнең күбесе тәрҗемә белән караган. «Татар телен яхшырак белсәм һәм аңласам, тәэсирләрем күбрәк булыр иде», – диючеләр дә булды.

Миңа калса, спектакль бик уңышлы сайланган иде. Тәрбияви моментларның күп булуы, аларның безне уйландыра алулары күңелләрне сафландыруга тагын бер адым булды.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.